ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2023 с.Старое Дрожжаное № 59

Яшьләр сәясәте өлкәсендә оешмаларга, чараларда катнашуга, авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру, яшьләрне хәрби-патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү, мәдәни-массакүләм чараларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы халкы өчен бәйрәмнәргә, социаль юнәлештәге башка чараларга бәйле юридик затларның чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне, юридик затларга, шәхси эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 22 декабрендәге 2385 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 19 гыйнварындагы 10 номерлы карары белән расланган (25.03.2022 ел, № 164 карар редакциясендә),Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан яшьләр сәясәте өлкәсендә оешмаларга, чараларда катнашуга, авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру, яшьләрне хәрби-патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү, мәдәни-массакүләм чараларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы халкы өчен бәйрәмнәргә, социаль юнәлештәге башка чараларга бәйле юридик затларның чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә

(каплауга) субсидияләр бирү тәртибенә, **6 пунктның алтынчы абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«сайлап алуда катнашучылар чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик заты капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып гамәлгә ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов